| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 12 » ноябрь 2020 с. Тюлячи № 492

2021 елга Теләче муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

ДБУ «Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге»нең 2020 елның 15 октябрендәге 01/1795 номерлы хатын карап, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга расларга:

1.1. Теләче муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны, кушымта нигезендә;

1.2. Сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын.

2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«12» 11 2020 № 492
карарына кушымта

Теләче муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориал дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучыга бер елга сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | уку-укытуның өчьеллык срогы | уку-укытуның дүртьеллык срогы | уку-укытуның бишьеллык срогы | уку-укытуның җиде еллык срогы | башлангыч һөнәри юнәлеш |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореографик сәнгать | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театраль сәнгать | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |

Эшләр идарәчесе И.Т. Һадиев